Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Новотроицк авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

08 ноябрь 2019 ел N 11

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Новотроицк авыл җирлегенең
Шөгерчә авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегенең Шөгерчә авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 29 ноябрендә, 9 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Новотроицк авыл җирлегенең Шегерчә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 350 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: торак пункттагы юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын медпунктның элеккеге бинасында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Шегерчә авылы, Үзәк урамы, 20 нче йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү кененә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Шөгерчә авылы, Үзәк урамы, 1 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз кеченә керә.

Новотроицк
авыл җирлеге башлыгы Н.Н. Лотфуллин